КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 март г.Казань № 338

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 29 декабрь, 666 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче; 2018 ел, 30 март, 197 нче, 2020 ел, 07 июль, 564 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«дәүләт органының кадрлар хезмәте (булган очракта) тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен, йә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 10 июль, 353 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 29 ноябрь, 580 нче, 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«дәүләт органының кадрлар хезмәте (булган очракта) тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен, йә хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр һәм дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хәрби билет күчермәсен (ул дәүләт хезмәткәрендә булса);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин